| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

25.10.2021 Казан ш. № 3237-р

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәре объектының саклау зонасын урнаштыру турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, «Атлант» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениеесе хатын исәпкә алып (04.10.2021 № 1256/05), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Территорияне куллануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текст һәм график тасвирламасында булган белешмәләр, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә, газ бүлү челтәре объектының («ТР, Лаеш районы, Усады ав., Ласковая ур. адресы буенча урнашкан Автомобиль газ тутыру компрессор станциясенә килүче тышкы газүткәргечнең саклау зонасы. Участокның кадастр номеры 16:24:150305:696») 199 м. озынлыктагы мәйданы, гомуми мәйданы 815 +/- 6 кв.м.лы территория рәвешендәге саклау зонасын урнаштырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән һәм өлешчә яки тулысынча күрсәтелгән газ бүлү челтәрләренең саклау зонасына туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәренең эксплуатация срогында Россия

Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**